ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 май 2026 ел № 4555

Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирү максатында, аларның керем күләменең һәм мөлкәт бәясенең чик кыйммәтләрен раслау турында

Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондындагы торак урыннар бирү максатында, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирү максатында, 2026 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең түбәндәге чик кыйммәтләрен билгеләргә:

1) гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керемнең чик кыйммәте – 50 806 сум 11 тиен;

2) гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең чик кыйммәте:

- ялгыз яшәүче граждан өчен – 2 279 826 сум;
- ике кешедән торган гаилә өчен – 4 559 652 сум;
- өч кешедән торган гаилә өчен – 6 839 478 сум;
- дүрт кешедән торган гаилә өчен – 9 119 304 сум;
- биш кешедән торган гаилә өчен – 11 399 130 сум;
- алты кешедән торган гаилә өчен – 13 678 956 сум;
- җиде кешедән торган гаилә өчен – 15 958 782 сум;
- сигез кешедән торган гаилә өчен – 18 238 608 сум.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары М.Ә. Фәттаховка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов